**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ**
**РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ**
**РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш.Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 22 » сентябрь 2025 ел № 4

**Татарстан Республикасы Әтнә районының башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс игълан итү турында**

Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуга бәйле рәвештә, 2025 елның 20 мартындагы "Бердәм дәүләт хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Әтнә муниципаль районы Уставының 46 маддәсе, Әтнә район Советының 10.10.2018 елдагы 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә таянып, Әтнә район Советы карар бирде:

1. Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс игълан итәргә.

1.1 Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына дәгъва кылучылардан конкурска документлар кабул итүне 2025 елның 26 сентябреннән 15 октябренә кадәр кертеп түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Олы Әтнә авылы, Ш.Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт, Әтнә муниципаль районы башлыгы урынбасары кабинеты, 08 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр, һәр көнне, ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш, телефон 2-10-04.

1.2 Конкурсны 2025 елның 17 октябрендә 09:00 сәгатьтә Әтнә район Советы бинасында үткәрергә, адрес: Олы Әтнә авылы, Ш.Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт.

2. Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатураларны карау буенча конкурс комиссиясе составын 6 кеше күләмендә расларга.

3. Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатураларны карау буенча конкурс комиссиясе составының яртысын 1 нче кушымта нигезендә 3 кеше составында расларга.

Әтнә районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатураларны карау буенча конкурс комиссиясе составының икенче яртысы Татарстан Республикасы Рәисы тарафыннан билгеләнүен игътибарга алырга (Татарстан Республикасы Рәисының 25.05.2023 елдагы 332 номерлы "Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре

вазыйфаларына кандидатураларны карау өчен конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында" Указы).

4. Әтнә район башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт формасын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

5. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында www.atnya.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әтнә муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе Р.Ш.Хисамиев